*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл** ________ __________________ **Шифр** _____________
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада КФУ**
**по предмету «Татарский язык»**
**заключительный этап (ответы)**
**2019-2020 учебный год**
**11 класс**

**I. Сүзтезмәләрне фразеологик гыйбарәләр белән алыштырып языгыз.** / Напишите словосочетания, заменив фразеологическими оборотами (10 баллов).

1. Акылы кысканың теле озын
2. Аз сөйлә, күп тыңла
3. Күз җитмәгән җиргә сүз җитә
4. Туры әйткән туганына ярамаган
5. Галим барда телең тый, оста барда кулың тый
6. Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар
7. Сабыр төбе – сары алтын
8. Тырышлык – зурлык, ялкаулык – хурлык
9. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар
10. Йөргән таш шомарыр, яткан таш мүкләнер

**II.Түбәндәге фонетик күренешләргә икешәр мисал языгыз:** / Напишите по два примера заданным фонетическим явлениям: (10 баллов).

1) Яңгыраулыкта-саңгыраулыкта ярашу *кардан, сандыктан*
2) Ирен гармониясе *төтен, болыт*
3) Тел арты һәм кече тел ассимиляциясе *алдынгы, иртәнге*
4) Борын ассимиляциясе *болыннар, урманнар*
5) Ирен ассимиляциясе *унбер, унбиш*

**III. Тотрыклы гыйбарә килеп чыгарлык итеп, сүзләрне тиешле формага куеп бәйләгез һәм кушымчаларны аңлатыгыз** / Соединяя слова, образуйте фразеологизмы и объясните окончания (10 баллов).

1) Энә, җеп, кадәр Энәсеннән җебенә кадәр
2) Авырту, җир, кагылу Авырткан җиргә кагылу
3) Авыз, өзү, бирү Авызыннан өзеп бирү
4) Кисү, ташлау, тырнак, тору Кисеп ташлаган тырнакка тормау
5) Өсте, тау, төшү, булу Өстеннән тау төшкәндәй булу

**IV. Җөмләгә синтаксик анализ ясагыз.** / Сделайте синтаксический анализ предложения. (10 баллов)

1) Көмеш сулар ага, 2) кошлар сайрый,
3) Шул чакларда бигрәк ямансу (Г. Бәширов)




*Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә*

**V. Кроссвордларны чишегез.** /Решите кроссворды

*1) Татар теле терминнарын табыгыз:*




**VI. Татар теле лексикасы турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз.** / Напишите о лексике татарского языка (20 баллов).

Лексика сүз дигән мәгънә аңлата. Ул грекча leksis сүзеннә алынган, телнең сүз байлыгы мәгънәсендә йөри. Кешеләрнең үзара аралашып яшәве һәм тормышның үзгәреп торуы аркасында, телнең сүз байлыгы арта. Сүзлек запасы баеган саен, кешенең сөйләме эчтәлекле, аңлаешлы һәм матуррак була бара. Телнең сүзлек составында кешеләрнең тормыш тәҗрибәсе, аларның образлы фикер йөртү сәләте, үткенлеге, зирәклеге чагыла.

Лексика дип теге яки бу телнең сүзлек составын (татар, рус, инглиз телләре), җирле сөйләшләрдәге (казан арты, минзәлә сөйләше) сүзләр җыелмасын, теге яки бу тел остасының (шагыйрь Г.Тукай), яки аерым бер кешенең сүзлек байлыгын (студент яисә укытучы), әдәби әсәрнең ("Тирән тамырлар" әсәре) сүзлек составын атыйлар.

Телдәге сүзләрне өйрәнү төрле тармакларга бүленеп алып барыла:

ономасиология - сүзнең атау вазыйфасы, әйберләргә, күренешләргә атама бирү, исем бирү закончалыклары өйрәнә;

семасиология - сүзләрнең мәгънәсен, мәгънәләр үсешен, үзгәрешен өйрәнә;

этимология - сүзнең тарихын, килеп чыгышын өйрәнә;

фразеология - телдә бер төшенчә белдерү өчен яраклашып катып калган тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә;

лексикография - телдәге сүзләрне җыю, теркәү, сүзлекләр төзү, сүзлекләрнең төрләрен өйрәнә;

ономастика - ялгызлык исемнәрен өйрәнә.

Сүз - телнең төп берәмлеге.

Сүзләрнең атау функциясе (сүзнең лексик билгесе) безне чолгап алган дөнья күренешләрен исемләргә мөмкинлек бирә.

Сүзнең мәгънәсе аның сөйләмдәге башка сүзләргә мөнәсәбәтеннән ачыклана.

Сүзләрне конкрет һәм абстракт, терминологик, образлы яки образсыз, эмоциональ яки эмоциональ булмаган мәгънәләре буенча да төркемләргә мөмкин.

Телнең сүзлек составында туры мәгънәле һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр бар.

Сүзнең төп мәгънәсе белән беррәттән, өстәмә мәгънәләргә дә ия булуы аның күпмәгънәлелеге - полисемия дип атала.

Төрле сәбәпләр аркасында (сүзнең аерым бер мәгънәсе югалу, теге яки бу төшенчәнең телдән бөтенләй югалуы) кулланылыштан төшеп калган сүзләр искергән сүзләр рәтендә өйрәнелә.

Искергән сүзләр тарихи һәм архаизмнарга бүленә.

Телдәге яңа сүзләрне неологизмнар дип атыйлар.

Бер генә халык та аерым, изоляцияләнеп яши алмаган. Элегрәк башка кабиләләр белән аралашу, соңга таба төрле халыклар, дәүләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә татар теленә теге яки бу телдән алынмалар килеп кергән.
Кулланылыш сферасы ягыннан татар теленең сүзлек составы берничә төркемгә аерыла. Иң зур урынны гомумхалык теле сүзләре алып тора. Гомумхалык теле сүзләре - барлык кешеләр (бу очракта - татар кешесе) өчен дә аңлаешлы, иң кирәкле сүзләр. Алар барлык стильләрдә дә кулланылалар. Икенче бер төркемне билгеле бер иҗтимагый катлам, билгеле бер коллектив, территория белән чикләнгән кешеләр куллана торган сүзләр тәшкил итә. Мондый сүзләргә диалекталь лексика, һөнәрчелек лексикасы, арго һәм жаргон сүзләр керә.

Һ.б.

**VII. "Татар теле бишеге" дигән темага татар теленең килеп чыгышы турында 80 сүздән ким булмаган сочинение языгыз. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее 80 слов) о происхождении татарского языка на тему «Колыбель татарского языка». Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов)

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |